| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 Казан ш. № 213-30/кс-2021

«Раифа ябык төр махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри мәгариф учреждениесе өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 11 декабрендәге 10-149/кс номерлы карары белән эчә торган суга билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2022-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемена төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Раифа ябык төр махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри мәгариф учреждениесе өчен эчә торган суга 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 2018 елның 11 декабрендәге 10-149/кс номерлы карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 10-16/кс, 28.10.2020 № 126-19/кс-2020 карарлары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2018 № 10-149/кс карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2021 № 213-30/кс-2021
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Раифа ябык төр махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри мәгариф учреждениесе өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 1 | «Раифа ябык төр махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри мәгариф учреждениесе* | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 24,40 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 25,15 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 24,41 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 24,41 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 24,41 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 24,86 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 24,86 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 25,94 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 25,30 |
| | | 01.07.2023 башлап | 25,30 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 31.12.2023 кадәр | |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге